МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.07.2020 г.Казань № 536

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 17 августында 6828 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының

20.06.2019 ел № 484, 16.08.2019 ел № 624, 14.11.2019 ел № 1023, 18.06.2020 ел № 436 боерыклары керткән үзгәрешләр) белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2020 елның
27 июлендәге 536 номерлы
боерыгы белән расланган

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм
социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын
төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен һәм аны күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне алу өчен гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны гариза бирүче тарафыннан, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | РФ Хезмәт министрлыгы 159н номерлы приказы белән расланган форма буенча гариза.<br><br>Гариза бирүче халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплексլы үзәкләрендәге өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра.<br><br>Гариза бирүче өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда, картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат-йортларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | РФ Хезмәт министрлыгының 159н номерлы приказы;<br><br>442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br><br>442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 6 ноябрендәге 870н номерлы «Гражданнарны махсус социаль хезмәт |

| | | |
|---|---|---|
| | | күрсәтүле стационар оешмаларга җибәрү тәртибен раслау турында» боерыгының 5, 6 пунктлары; Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2015 елның 29 апрелендәге 216н номерлы «Гражданга яисә социаль хезмәтләр алучыга стационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтүдән, шул исәптән вакытлыча баш тарту өчен сәбәпче була алган медицина ягыннан каршылыклар исемлеген, шулай ук вәкаләтле медицина оешмасының мондый каршылыклар булуын күрсәтә торган бәяләмә формаларын раслау турында» боерыгы (алга таба - РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының 216н номерлы боерыгы); |
| | Гариза бирүче психоневрологик интернатларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.; Россия Федерациясенең 1992 елның 2 июлендәге 3185-1 номерлы «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнарның хокукларын гарантияләү турында» |

| | | |
|---|---|---|
| | | Законының 41 ст. (алга таба - 3185-1 номерлы РФ Законы);<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының 216н номерлы боерыгы; |
| | Гариза бирүче акылы ягыннан зәгыйфь балалар өчен интернат-йортларда, физик кимчелекләре булган балалар өчен интернат-йортларда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 5 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>3185-1 номерлы РФ Законның 42 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының 216н номерлы боерыгы; |
| | Гариза бирүче инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән бала һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләредәге социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 11 ст. (алга таба - 181-ФЗ номерлы Федераль закон);<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының 216н номерлы боерыгы; |
| | Гариза бирүче социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.; |

| | | |
|---|---|---|
| | махсуслаштырылган учреждениеләрдә (бала һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 7 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 13 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының 216н номерлы боерыгы; |
| | Гариза бирүче аерым яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 8 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының 216н номерлы боерыгы; |
| | Гариза бирүче уку (тренировка) дәвамында яшәү курсы кысаларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка $8^1$ нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы "Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль |

| | | |
|---|---|---|
| | | хезмәтләрне стационар рәвештә күрсәтү тәртибен раслау турында" карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләрне стационар рәвештә күрсәтү тәртибенең 8.4.2 пункты; РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының 216н номерлы боерыгы; |
| | Гариза бирүче гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләрендә гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәләрендә ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 9 нчы кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.; 908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары; |
| | Гариза бирүче халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләрендәге социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән бала һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 10 нчы кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.; 181-ФЗ номерлы Федераль законның 11 ст.; 908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары; |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза бирүче сукырлар һәм начар күрүчеләрне социаль реабилитацияләү үзәгендә ярымстанционар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 11 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>181-ФЗ номерлы Федераль законның 11 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары; |
| | Гариза бирүче өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын төзү буенча пилот проектында катнашучы социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга көндезге төркемнәрдә ярымстанционар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә 2020-2022 елларда әлеге Регламентка 11[1] нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 31 декабрендәге 1101 номерлы "Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләрне ярымстационар рәвештә күрсәтү тәртибен раслау турында" карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләрне ярымстационар рәвештә күрсәтү тәртибенең 6.4.2 пункты; |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза бирүче гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләрендәге гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәләрендә өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә әлеге Регламентка 12 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә документлар тапшыра. | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>181-ФЗ номерлы Федераль законның 11 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары; |
| | Документларның күчермәләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, оригиналлары күрсәтеп тапшырыла һәм Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты тарафыннан раслана.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь чыганакларда шәхсән яисә почта аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы "Электрон имза турында" Федераль закон (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закондагы $21^1$ һәм $21^2$ статьяларының таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә электрон йөрткечләр кулланып, шулай ук гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән "Интернет" челтәре аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә гариза | 442-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 16 ст.;<br>908 номерлы Тәртипнең 7, 8, 9 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | бирүче шәхесен таныклый торган документ күрсәтә. Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза законлы вәкил яки гариза бирүче мәнфәгатьләрен кайгырткан башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре тарафыннан бирелгәндә, вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен раслый торган документлар күрсәтелә»; | |

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында:

сигезенче абзацны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән алмаштырырга:

«социаль адаптация үзәкләрендә аерым яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә әлеге Регламентка 19 нчы кушымта нигезендә;

уку (тренировка) дәвамында яшәү курсы кысаларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтү турында әлеге Регламентка $19^1$ нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә;»;

унберенче абзацны түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән алмаштырырга:

«сукырлар һәм начар күрүчеләрне социаль реабилитацияләү үзәгендә ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү турында әлеге Регламентка 22 нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә;

өлкән яштәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын төзү буенча пилот проектында катнашучы социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан өлкән яштәге гражданнарга һәм инвалидларга көндезге төркемнәрдә ярымстационар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән бергә 2020-2022 елларда әлеге Регламентка $22^1$ нче кушымтада китерелгән исемлек нигезендә;»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле $8^1$ нче кушымта өстәргә:

«$8^1$ нче кушымта
Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә
мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр
күрсәтүнең хосусый программасын
төзү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына

Гражданны
уку (тренировка) дәвамында яшәү курсы кысаларында
социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүгә
мохтаҗ дип тану өчен кирәкле,

гариза бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) территориаль органына яшәү урыны буенча тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документ бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасы * | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасында күрсәтелгәнчә |
| 2. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен раслаучы документлар ** | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнарда билгеләнгәнчә |
| 3. | Стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтүләр өчен медицина каршылыклары булмау турында бәяләмә | медицина оешмалары | сәламәтлек турында белешмәдә күрсәтелгәнчә |
| 4. | Интеллектның җиңел яки уртача бозылуы (МКБ-10 буенча диагноз: F70, F71) яки югары функцияле аутизм (Аспергер синдромы) (МКБ-10 буенча диагноз: F 84.5) булуын, шулай ук алкоголь һәм наркотик бәйлелекнең һәм качуга һәвәслекнең булмавын раслый торган белешмә | медицина оешмалары, Татарстан Республикасының психоневрология интернатлары (тиешле психоневрологик интернатның социаль хезмәт күрсәтүләрен алучыларга) | законнарда билгеләнгәнчә |

*- инвалидларның федераль реестрында тиешле белешмәләр булмаган очракта инвалидларга тапшырыла;

* - гаризаны гариза бирүченең законлы вәкиле биргән очракта, билгеләнгән тәртиптә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затларга тапшырыла.»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 11[1] нче кушымта өстәргә:

«11[1] нче кушымта
Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына

Гражданны
уку (тренировка) дәвамында яшәү курсы кысаларында
Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) территориаль органына гариза бирүче тарафыннан яшәү урыны буенча тапшырылырга тиешле
өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын төзү буенча пилот проектында катнашучы
социаль хезмәтләр күрсәтүчеләр тарафыннан өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга
көндезге төркемнәрдә, 2020-2022 елларда гражданны социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен
кирәкле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документ бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен раслаучы документлар * | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнарда билгеләнгәнчә |
| 2. | Инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасы** | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасында күрсәтелгәнчә |
| 4. | Өлкән яшьтәге кешенең хәтер белән проблемалары | медицина оешмалары | законнарда билгеләнгәнчә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (деменция, картлык астениясе) (МКБ-10 буенча диагноз: F00-F03, R54) яки когнитив бозылулар (МКБ-10 буенча диагноз: F70, F71) булуын раслый торган белешмә*** | | |
| 5. | Интеллектның җиңел яки уртача бозылуы (МКБ-10 буенча диагноз: F70, F71) яки югары функцияле аутизм (Аспергер синдромы) (МКБ-10 буенча диагноз: F 84.5) булуын, шулай ук алкоголь һәм наркотик бәйлелекнең һәм качуга һәвәслекнең булмавын раслый торган белешмә**** | медицина оешмалары, Татарстан Республикасының психоневрология интернатлары (тиешле психоневрологик интернатның социаль хезмәт күрсәтүләрен алучыларга) | законнарда билгеләнгәнчә |

* - гаризаны гариза бирүченең законлы вәкиле биргән очракта, билгеләнгән тәртиптә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затларга хезмәт күрсәтүгә китерелгәндә тапшырыла;

**- инвалидларның федераль реестрында тиешле белешмәләр булмаган очракта инвалидларга тапшырыла;

*** - өлкән яшьтәге гражданнарга тапшырыла;

****-18 яшьтән башлап һәм өлкәнрәк инвалидларга тапшырыла.»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле $19^1$ нче кушымта өстәргә:

«$19^1$ нче кушымта
Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә
мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр
күрсәтүнең хосусый программасын
төзү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына

Гражданны
уку (тренировка) дәвамында яшәү курсы кысаларында
социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүгә
мохтаҗ дип тану өчен кирәкле,
дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында торган, һәм гариза бирүче яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт,

халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) территориаль органына мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы булган документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документ бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасы | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасында күрсәтелгәнчә»; |

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 22[1] нче кушымта өстәргә:

«22[1] нче кушымта
Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә
мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр
күрсәтүнең хосусый программасын
төзү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына

Гражданны
өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын төзү буенча
пилот проектында катнашучы социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга көндезге төркемнәрдә ярымстанционар рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтү турында 2020-2022 елларда
социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында торган, һәм гариза бирүче яшәү урыны буенча
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
(шәһәр округындагы) территориаль органына
мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы булган документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документ бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 1. | Инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасы | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасында күрсәтелгәнчә». |